Равил Әмирхан,
тарих фәннәре докторы.
28.09.2002.

# ЯҢА БИСТӘ

Татарстан башкаласы Казан тарихында Яңа Бистә үтә үзенчәлекле урын тота. Һәм бу тарихның гаҗәп гыйбрәтле сәхифәләре бар. XVIII гасырның урталарына кадәр «гомуми» Татар Бистәсе яшәп килсә дә, Яңа Бистә дигәне әле булмый. Ничек кенә сәер тоелмасын, аның барлыкка килүе нигездә бер мәгълүм шәхеснең, ягъни Лука Канашевичның җимергеч «эшчәнлеге» белән бәйле. Әрхәрәй (архирей) Лука Канашевичны татарлар «Аксак Каратун» дип йөрткәннәр.

Мәгълүм булганча, Мөдһиш Иван (Иван Грозный) Казанны 1552 елның 2 октябрендә ала һәм исән калган татарлар элекке башкалада яшәү түгел, аңа керү хокукыннан да мәхрүм ителә. Әмма колонизация патша хөкүмәте алдына яңа таләпләр дә куя. Әйтик, буйсындырылган халык белән элемтә урнаштыру өчен урыс феодаль администрациясенә йомышчылар кирәк була. Ә аларның һәрвакыт кул астында булуы хәерле. Шунлыктан «йомышлы» (служилый) татарлар катлавы яу көннәрендә үк туплана башлый. Нәтиҗәдә урыс администрациясенә лояль яки Мөдһиш Иван явына каршы чыкмаган аерым (башлыча «йомышлы») татарларга Кабан күле аръягында (хәзерге К.Насыйри, Ф.Кәрим урамнары тирәләре) таулы-чокырлы, баткаклы, черек табигатьле җиргә алачыклар салып урнашырга рөхсәт бирелә. Әлеге «ташландык» төбәк XVI гасырда шәһәрнең үзеннән шактый еракта булып, Казанга административ яктан мөнәсәбәте юк дәрәҗәсендә аз була. Шулай итеп, 1552-1553 елларда Казан шәһәреннән читтә Татар Бистәсе барлыкка килә.

Этно-социаль төркем буларак, «икенче», ә бәлки әле «өченче» сортлы итеп каралган йомышчыларга бернинди хезмәт хакы түләнмәгән, фәкать урыс интересларына зарар китермәслек дәрәҗәдә һөнәр-сәүдә эшләре белән шөгыльләнергә генә мөмкинлек бирелгән.

XVI гасыр азагына таба бу бистә, котсыз рельефлы, бозык һавалы җирдә урнашуына карамастан, һәр җәһәттән төзекләндерелеп, даими халкы булган татар үзәгенә әверелә һәм Казанда урнашкан урыс администрациясенең игътибарын торган саен ныграк җәлеп итә бара. Бу вакытларда бистәдә 1,5 мең чамасы татар гаиләсе (якынча 6 мең кеше) яши. Кырмыска урынына эшләгән халык тырышлыгы нәтиҗәсендә бистә һаман үсә, киңәя һәм XVII гасыр башларында Кабан күленең көньяк-көнбатыш яры буйлап Пләтән (Плетени) авылына барып тоташа.

Яңа хуҗаларга никадәр генә лояль булсалар да, Мәскәү хөкүмәте «йомышлы» татарларга карата да бик кырыс сәясәт үткәрә. Мәсәлән, XVI гасырның азагына таба Бистә татарлары мәчет биналары салып, вөҗдан ирегенә өмет баглый. Тик җирле түрәләрнең шикаяте аркасында Мөдһиш Иван улы Федор патша бар булган мәчетләрне җимерергә, ә яңаларын бүтән беркайчан да салдырмаска боерык бирә (1593). Махсус язма кенәгәләрдә (әйтик, 1646 елда) Казанның башка бистәләре белән беррәттән Татар Бистәсе дә теркәлгән һәм, күрәсең, инде шәһәрнең посад диварлары артындагы состав бер өлеше булып саналган. Бу чорда татарларга шәһәрдә күренергә инде яраса да, крепостька (хәзергечә: кремль) үтеп керү үлем куркынычы астында катгый тыелган булган. XVII гасырның урталарында Бистә татарларының саны төрле сәбәпләр аркасында нык кына кимегән һәм чама белән 3,6 мең кеше тәшкил иткән.

Иске Бистә «карын»ында туган Яңа Бистәнең барлыкка килүе татарларны XVI гасырдан кала иң рәхимсез кысу һәм җәберләү чорында туры килә. Аның кыскача тарихы болай. 1748 елның көзендә Хәрби министрлык, крепостьлар әйләнәсендәге (130 сажиннан якын урнашкан) биналарны алдырырга дигән фәрман чыгара. Әлеге күрсәтмә нигезендә Казан крепосте эчендәге һәм аның тирәсендәге өч монастырь, алты чиркәү, күп санлы

христиан руханилары яши торган йортлар да башка бер урынга күчерелергә тиеш була. Ләкин шәһәр хуҗалары, ни хикмәттер, озак вакыт «җайлы урын» таба алмый интегә.

«Ярдәм» һич көтмәгәндә килә. 1749 елның 3 май төнендә Татар Бистәсендә зур янгын чыгып, кыска гына вакыт эчендә бөтен шәһәрне диярлек чолгап ала. Янгын нәтиҗәсендә Татар Бистәсеннән көл белән күмер генә кала. Ләкин Казанның төп, урыс өлеше дә зур зыян күрә. Әйтик, крепостьның үзендә генә дә үзәк чиркәү, әрхәрәй йорты, Спас һәм Троица монастырьлары, Вознесение чиркәве, губернатор сарае, үзенең архивы белән губерна канцеляриясе һәм башка корылмалар юкка чыга. Шәһәрнең күп кенә халкы йорт-җирсез кала. Менә шушы коточкыч афәтне Казан әрхәрәе Лука Канашевич барлык татарларны Татар Бистәсеннән куу өчен корал итеп файдалана да инде. Императрица Елизавета Петровнага ул: татарларга Алланың каһәре төште, алар өстенә күктән ут яуды, дип яза һәм бар көчен яныпп «бушаган» урынга урысларны күчереп утыртуга сарыф итә башлый. Урысларга яңадан төзенү өчен иң кулай урын дип буш һәм иркен Арча кыры саналса да, төп максат татарларны куу булганга, Канашевич Арча кыры вариантын кире кага. Әрхәрәй планы буенча, янган Татар Бистәсе урынын поплар, православныйлар һәм яңа чукынганнар, Раиф һәм Седьмиозер монастырлары каралтылары, хатын-кыз монастыре, башка чиркәү һәм христиан зиратлары алырга тиеш була.

Ул арада крепость тирәсеннән күчерелергә тиешле поплар губерна идарәсенә гариза яза һәм татарларны элекке урыннарына йорт салудан катгый тыюларын таләп итә. Җирле администрация бу таләпне канәгатьләндерә. Канашевич тарафдарларының теләкләрен үтәп, губерна идарәсе Сенатка Татар Бистәсен яшәү өчен бернинди уңайлыклары булмаган Әмәт чокырына (хәзерге Ометьево) күчерү турында тәкъдим кертә. «Татарлар - терек асраучылар, аларга мал үрчетү өчен Әмәт тирәсе иң кулай урын», дип тә искәртелә.

Гаять авыр хәлдә, йортсыз, җирсез калган татарлар, киңәш итешеп һәм беркадәр акча җыеп, Сенатка үз вәкилләрен җибәрә. Төп максатлары - янган җирләргә яңадан йортлар салу була. Лука Канашевич җитәкләгән руханилар исә тагын да «үтемлерәк» чарага керешә. Бу җирләрдән татарларны өркетер өчен «тәре походы» оештыра: зур шау-шулар белән булачак чиркәү урыны билгеләнә, анда тәре кадаклау (беркетү) мәрасиме (церемониясе) үткәрелә. Ул тәрегә кагылу үлем җәзасына торырлык иң зур җинаять дип игълан ителә.

Бик зур һиммәт сарыф итү һәм чыгымнар тоту исәбенә Бистә «йөрешчеләре» Сенаттан үзләренең элекке җирләренә рөхсәт алуга ирешә. Озак та үтми, татарлар төзенә, кура-каралтыларын, бакчаларын һ.б. тергезә башлый. Моны күреп, Лука Канашевич ерактагы бер агач чиркәүне сүттереп, теге тәре кагылган урынга ашыгычлык белән китереп тә өйдерә. Ашып-пошык салынган чиркәү әзер булуга әрхәрәй Сенатка хәбәр юллый, мондагы татарларның тамырын корытуны сорый. Язмада мондый юллар да була: «Дин дошманнары - татарларга уңайлык ясыйм дип, әлеге изге храмны сүттерү - чиркәүне, дәүләтне, Урыс илен хөрмәтсезләү булыр иде».

Сенатка шул җитә кала, ул әле күптән түгел генә татарлар файдасынарак кабул иткән карарын юкка чыгара. Инде гайрәтләнеп киткән Канашевич тарафдарлары әкренләп тернәкләнә башлаган Татар Бистәсенә җимергеч һөҗүм оештыра: йөзәр кешелек төркемнәр, йорт борынча йөреп, мичләрне вата, морҗаларны ишеп төшерә, бакчаларны таптый һәм юк итә, алма, чия агачларын кисә, тире, сабын кайнату кярханәләрен җимерә һ.б. Татар өстенә XVI гасырны хәтерләткән дәһшәт ябырыла. Чыдар әмәле калмаган халык күсәккә ябыша башлый. Коточкыч рәнҗетү, кыйнау, погромнарга карамастан, татарларның байтагы үз урынында кала, гаделлек эзләп Сенатка кешеләр җибәрә, яшәү хакына зур корбаннар бирә. Ләкин халыкның зур өлеше (400 гә якын хуҗалык) барыбер көчләп Пләтәннән ерак булмаган Поповка авылы урынына күчерелә. Шул чорлардан башлап элекке урында калган Татар Бистәсе – «Иске Бистә», Поповкага күчерелгән өлеше «Яңа Бистә», дип йөртелә башлый. Яңа Бистәгә нигез 1751 елның 6 июнендә салына. Әмма

күчену, иске урынга кайтырга омтылыш белән бәйле ыгы-зыгы, дау әле озак еллар буена дәвам итә.

Татарны үзләштергән җиреннән куу, рәнҗетү фаҗигасен күренекле урыс тарихчысы Н.Ф.Калинин мондый сүзләр белән тасвирлаган иде (мәгънәсенә хилафлык килмәсен өчен оригиналдагыча китерәбез): «Дворянская администрация и церковники создали для казанских татар в середине XVIII в. невыносимые условия, образовав своего рода гетто - Ново-Татарскую слободу, четверть века буквально превращавшуюся в остров и урезанную вдвое Старо-Татарскую слободу, зажатую в мешок из церковных земель».

Поповка урынындагы Яңа Бистәнең шәһәр белән бәйләнеше гадәттән тыш авыр була. Чөнки Поповка яз көне ике ай ярымга утрауга әверелә торган түмгәк сыман кечкенә бер калкулыкта урнашкан, ә тирә-ягында сазлыклар җәелеп яткан. Татарлар менә шушы коточкыч тыгызлыкта һәм шыксыз җирдә яшәргә дучар ителә. Яз көннәрендә Идел ташыгач кешеләр шәһәргә айлар буе көймә белән йөреп изалана. Бу хәл Яңа Бистәнең үсешенә, икътисади яктан алга китешенә гаять начар йогынты ясый. Шуңа күрә татарлар элекке (Иске Бистә) урынына кайтаруны даулауларын дәвам итә. Анда булмаса, башка берәр җайлырак урын чыкмасмы дигән өмет белән яши.

Татарлар чирек гасыр чамасы шушы геттода интеккәч, илдәге вәзгыять кискен үзгәреп китә. 1773 елда самодержавие нигезләрен дер селкеткән куәтле крестьяннар хәрәкәте кузгала. Тарих сәхнәсенә «Петр Федорович патша» исеме белән Емельян Пугачев чыга. Бу хәрәкәткә һәр яктан рәнҗетелгән Яңа Бистә татарлары да кушылмагае дип, хөкүмәт аларга беркадәр ташламалар ясауны мәгъкуль күрә. Җир биләүче аерым урыс түрәләрен матди яктан кызыксындырып һәм татарларны беркадәр үгетләп, хакимият татарларга яңа урын билгели. Шуның нәтиҗәсендә татарлар элеккесеннән беркадәр уңайрак саналган һәм шәһәргә якынрак булган бүгенге Яңа Бистә урынына (М.Гафури, Мехчылар урамнары тирәсе) күчерелә (1773-1774).

Яңа Бистә халкы, Иске Бистә татарлары төсле үк, Пугачев явына теләктәшлек күрсәтә, байтак кешеләр аның гаскәренә кушыла. 1774 елның 12 июлендә Пугачев, кремльдән кала, Казанны ала. Халык үзенең изүчеләренә үч итеп бөтен агач Казанны яндыра, ләкин Иске Бистәгә дә, Яңа Бистәгә дә ут салынмый, алар имин кала.

Яңа Бистәгә, элекке урындагысы төсле үк, сазлыклар, иңкүлекләр, язгы Идел ташуларыннан күргән уңайсызлыклар хас булса да, халык аны яшәргә уңай бер хәлгә китерә, төзекләндерә, һөнәр, кәсеп, сәнәгать үзәгенә әйләндерә. Бистә XVIII гасыр ахырларында кызу темплар белән үсә һәм XIX гасыр башында шәһәр сызыгына кереп бетә. Казан административ яктан 6 полиция участогына (полицейская часть) бүленгән вакытта Яңа Бистә аның 5 нче өлешенә керә.

Хасил булу чорыннан ук биредә һөнәрчелек киң җәелә, читек каю, калфак чигү, кәләпүш тегү, алтын-көмештән, бронза, сөяк һәм агачтан зиннәтле әйберләр ясау алга китә. Соңрак (XIX гасыр азагында) Яңа Бистәнең шундый бер һөнәрчесе гаиләсендә сабый Тукай берара үзенә шәфкатьле әти белән әни таба.

Яңа Бистә тора-бара татарның сәнәгать, сәүдә үзәге генә түгел, беркадәр күләмдә мәдәни, рухи мәркәзе ролен дә үти башлый. XIX-XX гасырларда биредә Исмәгыйль Үтәмишевның бәз буяу һәм сабын заводы, Үтәмишев һәм К° сенең буяуга ману һәм мамык фабрикасы, Габдрахман Галикәевнең сабын, Якуп Козловның («Кәҗә Якуп») сафьян заводы, тире эшкәртү кярхәнәләре һ.б. эшли. Шул ук чорларда Яңа Бистә халкы өч мәхәлләгә оешып яши, өч мәчеткә йөреп, имамнарының вәгазен тыңлый. Рәсми статистик материалларда әлеге намаз йортлары 9,10 һәм 11 нче номерлы мәчетләр булып йөри. Агач мәчетләр XVIII гасырның азагында ук салына, ә менә беренче таш мәчет (М.Гафури урамы, 34а) Мәчкәрә бае Габдулла Үтәмишев акчасына бина кылына. Риваятьләргә күрә, ул 1552 елда Казанны саклап шәһит киткән бабаларыбыз сөякләре өстендә «утыра». 1809 (1810) елдан бу мәчеттә Әмирхан бине Габделмәннан имамлык кыла башлый, мәшһүр «Әмирхания»

мәктәп һәм мәдрәсәләренә нигез салып җибәрә. Аның дин, мәгърифәтчелек, милли мәдәнияткә хезмәт итү юлындагы һиммәтләрен традиция буенча XX гасырның 20 нче еллар уртасына кадәр Хөсәен, Зариф, Нәҗип, Рабига, Сәгадәт, Фатих, Ибраһим Әмирханнар уңышлы дәвам иттерә. 1898 елда Яңа Бистәдәге «Әмирхания» мәдрәсәсендә Гаяз Исхакыйның мөгаллимлек кылганы билгеле.

Әлеге җәһәттән Яңа Бистә имамнары, мәгърифәтчеләре булган Кәшшаф Тәрҗәмани, Садыйк Иманколый, Салимҗан Галиев, Әфтәхетдин Тәрҗемани, Ибраһим Халитов, Каюм Бәдигый һ.б. исемнәрен телгә алу урынлы булыр. Мәктәп-мәдрәсәләр димәктән, аларның саны Яңа Бистәдә байтакка җиткән: «Әмирхания» мәктәбе һәм «Әмирхания» мәдрәсәсе, «Кәҗә Якуп» мәктәбе һәм «Кәҗә Якуп» мәдрәсәсе, «Сәет» мәдрәсәсе, «Мөстәкыйм» мәдрәсәсе, «Бафилов» мәдрәсәсе һ.б. Рәсми документларда аларның исемнәре «Бафиловское», «Сеитовское», «Амирхановское», «Якуповское» һ.б. дип йөртелгән. «Якуповское» медресе («Кәҗә Якуп» мәдрәсәсе дигәне) совет чорында «Каюм Насыйри исемендәге 44 нче башлангыч мәктәп» булып китә. Болардан тыш Яңа Бистәдә революциягә кадәр Бибирабига Әмирханиянең кызлар мәктәбе, «Яңа Бистә мәдрәсәләре каршындагы урыс класслары» һ.б. эшли. Әйтик, бу урыс классларында 1905 елда 34 бала укый. Бүгенге көндә бу милли уку йортларының матур традициясен № 1 татар гимназиясе дәвам итә. Күп еллар дәвамында 35 нче номер йөрткән бу белем учагы 1990 еллар башына кадәр Казанда бердәнбер дип әйтерлек татар мәктәбе булып калган иде.

Үткән гасырлардагы рухи алгарышның инеш башында мәгълүм дәрәҗәдә Яңа Бистәдә гомер сөргән атаклы Хәлфиннәр династиясе торган. Үзләре мәктәп-мәдрәсәләр тотмаса, имамлык вазифасын башкармаса да, алар (Сәгыйть, Исхак, Ибраһим) татар мәдәнияте, татар теле үсешенә зур өлеш керткән. Әйтик, Сәгыйть Хәлфин Казан гимназиясендә татар теле укыта, 1778 елда Мәскәүдә беренче татар әлифбасын бастырып чыгара, 1785 елда урысча-татарча сүзлек нәшер итә. Сәгыйтьнең улы Исхак, оныгы Ибраһим да бу өлкәдә күп кенә мактаулы эшләр башкара.

XIX-XX гасыр башына кадәрге чорда Яңа Бистә Казанның иң начар төзекләндерелгән, административ, икътисади, медицина ярдәме күрсәтү җәһәтләреннән иң артта калган төбәкләрдән санала. Биредә патша хөкүмәтенең татарларга «күркәм» мөнәсәбәте аерымачык ярылып ята. 1917 ел мәгълүматлары буенча, биредә 5890 кеше яшәсә дә, Бистәдә ни электр, ни газ лампалары янмый, ни трамвай йөрми, берәр аптека яки дәвалау пункты эшләү түгел, гади фельдшеры яки акушеркасы да булмый. Бу хәл совет чорында да озак еллар дәвам итә. 1920 еллар уртасында да әле Яңа Бистә сазлыклар уртасында утыра, көз, яз айларында бихисап утраучыкларга урнашкан Венеция каласын хәтерләтә. Бистә картлары искә алганча, бу чорларда, кая карама - басма, көймә, саллар күзгә ташлана. Сал, көймә, басмалардан Бистә халкын бары тик 1950 еллар уртасында Куйбышев ГЭСы төзелү уңае белән салынган дамба гына коткара.

Яңа Бистәнең 1,5 гасыр буена калыпланган кыяфәте 1928-1930 (Казан мех фабрикасы һәм берләшмәсе төзелгәч), бигрәк тә 1941-1945 елларда (бирегә Ленинградтан күп кенә хәрби заводларны күчергәч) кискен үзгәрә. Алар Бистәнең үзәк урамнарындагы бик күп шәхси йортларны, тарихи биналарны бөтен хуҗалыгы-һөнәрчелеге белән «йота». 1941-1945 елгы совет-герман сугышы азагында мондагы предприятиеләрдә 40 меңләп эшче исәпләнә. Бистәнең төп халкы өметсез азчылыкка калгач, аның «татарча төсе» нык «уңа». Яшәп килгән мәчетләрнең төп өлешен гамәлдән чыгаргач (кайберләре цехларга әйләндерелә), татар зиратына юлны зур таш дивар белән томалагач, Яңа бистәнең кайчандыр татарларга булган нисбәтен хәзер санаулы гына корылмалар («Иске таш мәчет», 1 нче татар гимназиясе һ.б.) гәүдәләндерә.

Хәзерге «Яңа Бистә», татар төбәген аңлатмыйча, географик һәм тарихи төшенчә буларак кына йөри дисәң дә ялгыш булмастыр. Казанның төрле районнарында фатирлар

алып таралышып беткән бик күп «яңа бистәлеләр» (карт буын инде бакый дөньяга күчеп беткән) туган төбәкләрен инде юксыну, сагыну хисләре белән генә искә алырга мәҗбүрләр.

Ләкин шунысын да искәртергә кирәк. Революциягә кадәр Яңа Бистә татарлары шәһәр халкының чама белән 6-7 процентын гына тәшкил итсә дә (Иске Бистә, Бишбалта һ.б. белән 15-16 процент), бөтен татар милләте өчен моның әһәмияте ифрат дәрәҗәдә зур булган. Яңа Бистәдә тыгыз тупланып утырган, рухи яктан береккән татарлар аның шәһәр (матди һәм мәдәни) культурасын үстереп кенә калмаган, бәлки татарларның милләт булып калыплануында да мәгълүм күләмдә үзәк вазифасын үтәгән.